


Августыннын беренче декадасында Казан шәһәренен 183 нче гимназиясе базасында Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан мәгариф һәм фән хезмәткәрләренен август киңәшмәсе кысаларында милли мәгариф секциясе утырышы һәм Россия Федерациясе тобәкләрендәге белем оешмалары житәкчеләре һәм татар теле укытучылары очен семинар-киңәшмә vтте.

Киңәшмәдә Россия Федерациясе тобәкләрендә милли мәгариф очен жаваплы кураторлар, милли мәктәп житәкчеләре, татар теле укытучылары катнашты. Мордовия делегациясен РМ мәгариф министрлыгы белгече Надежда Васильевна Салмова житәкләде. Делегат буларак Ромоданово районы Белозерье урта мәктәбе директоры Эльвира Искандәр кызы Киреева, регионыбызнын мактаулы татар теле һәм әдәбияты укытучылары - Сания Спартак кызы Саляева (Рузаевка районы Татар Пешлә урта мәктәбе), Светлана Равиль кызы Поташова (Кадошкино районы Латышовка урта мәктәбе), Луиза Низаметдин кызы Смакаева (Ләмберә районы Кривозерье урта мәктәбе), Надия Мухаррям кызы Максутова (Ләмберә районы Пензятка урта мәктәбе) катнаштылар.

Киңәшмә “Янартылган федераль дәvләт белем бирv стандартларын гамәлгә ашыру шартларында туган телләр укытунын методик аспектлары” темасына багышланган иде.
– Хәерле кон, хормәтле милләт сагында торучы укытучыларыбыз, тобәкләрдә БТК канаты астында эшләvче татар оешмалары житәкчеләре! Барыгызны да Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Ботендонья татар конгрессы Милли Шурасы рәисе Васил Шәйхразыев исеменнән сәламлим! Без барыбыз да милләт сагында,

без анын vсеше очен жаваплы. Читтә яшәvче милләт-тәшләребезнен карашы да Татарстанга, Казанга юнәлгән. Шул ук вакытта, Татарстан да читтәге милләттәшләребезне, милли мәктәпләрне, анын лидерларын, укытучыларын барлап, саклап, элемтәдә булып, методик ярдәм кvрсәтеп, дәреслекләр белән тәэмин итеп, жәйге аланнар булдырып тора, – диде Данис Шакиров (Ботендонья татар конгрессы Милли Шура рәисенен беренче урынбасары – Ботендонья татар конгрессы Башкарма комитеты житәкчесе) чыгышында.
Ул шулай ук укытучыларны хокукый яклау һәм аларга методик ярдәм кvрсәтv мәсьәләләренә, милли юнәлештә югары уку йортларында белгечләр әзерләv мәсьәләләренә дә тукталып узды.



Татарстан Республикасы Мә-гариф һәм фән министры Илсур Һәдиуллин да укытучыларны сәламләде.
– Татар теленә һәм әдәбиятына карата мәхәббәтегезне, нинди генә авырлыклар булуга карамастан, vз жирлекләрегездә, регионнарыгызда vстергәнегез очен зур рәхмәт сезгә! Бу безнен бергә алып барган уртак хезмәтебез. Барыгызга да кочле рух, матур сvз, исәнлек-саулык телим, – диде ул.
Кинәшмә кысаларында янартылган Федераль дәvләт белем бирv стандартларын гамәлгә ашыру һәм федераль белем бирv программаларын гамәлгә кертv шартларында туган телләрне укыту мәсьәләләре буенча чыгышлар тынланган һәм мастер-класслар vткәрелгән.
- Тошке аштан сон барлык катнашучылар очен пленар кинәшмә оештырылган иде. Чара кысаларында янартылган федераль дәvләт белем бирv стандартларын гамәлгә ашыру һәм федераль белем бирv программаларын гамәлгә кертv шартларында туган телләрне укыту мәсьәләләре буенча чыгышлар ясалды. Катнашучылар очен кvргәзмәләр, мастер-класслар, методик мастерскойлар эшләде: белем бирv процессында яналыклар белән таныштык. Әдәби марафонны оештыручы Раил Гатауллин белән дә кvрешергә насыйп булды. Салаватнын яна сезон концертын карау бәхете дә тиде. Гадәттәгечә, Казан безне жылы каршы алды,- диде аралашканда Сания Спартак кызы Саляева.

**Наилә НАСЫРОВА**